**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 13 июль | № 512

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм кайберләре үз көчен югалткан дип санау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын тормышка ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 1999 ел, 7 май, 284 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 3 июль, 465 нче; 2002 ел, 5 сентябрь, 523 нче; 2005 ел, 25 август, 419 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 493 нче; 2007 ел, 12 октябрь, 556 нчы; 2008 ел, 25 август, 608 нче; 2008 ел, 26 сентябрь, 710 нчы; 2012 ел, 29 февраль, 178 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 799 нчы; 2013 ел, 28 март, 212 нче; 2013 ел, 31 август, 621 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында инвестиция проектларын тормышка ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтаның 5.1 нче пунктына «мөһер белән расланган» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтаның 2 нче пунктына «(мөһер)» сүзеннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен, «мөһер» сүзеннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының инновация инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2013 ел, 4 июнь, 384 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 сентябрь, 699 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының инновация

инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктның сигезенче абзацында «гариза бирүче мөһере белән расланган» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларын төзү» чарасы буенча федераль субсидия алуга Татарстан Республикасыннан уртак гаризага кертүгә дәгъва итүче гаризаларны сайлап алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 6 октябрь, 728 нче карары белән расланган «Сәнәгать (индустриаль) паркларын төзү» чарасы буенча федераль субсидия алуга Татарстан Республикасыннан уртак гаризага кертүгә дәгъва итүче гаризаларны сайлап алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.2 нче пунктта «юридик зат мөһере белән» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 декабрь, 944 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы пунктның икенче һәм бишенче абзацларында «оешма мөһере белән» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктның сигезенче абзацында «мөһер белән расланган», «үзәкнең мөһере белән» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы территориясендә аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләүне тәртипкә китерү турында» 2001 ел, 28 февраль, 98 нче;

«Бердәм республика лицензияләр реестры турында» 2001 ел, 4 октябрь, 721 нче;

«Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлеген үстерү өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 9 июнь, 504 нче;

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җиһазлар, күчемсез мөлкәт сатып алуга, финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча түләүләр кертүгә бәйле чыгымнарны өлешчә финанслау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 30 июль, 642 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 ел, 17 ноябрь, 1004 нче;

«Әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм квалификация күтәрүгә, шулай ук эшмәкәрлек грамоталылыгын һәм эшмәкәрлек компетенцияләрен үстерүгә бәйле булган белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән файдалану буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен гаризалар сайлап алу конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 28 ноябрь, 1041 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җиһазлар, күчемсез мөлкәт сатып алуга, финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча түләүләр кертүгә бәйле чыгымнарны өлешчә финанслау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 30 июль, 642 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җиһазлар, күчемсез мөлкәт сатып алуга, финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча түләүләр кертүгә бәйле чыгымнарны өлешчә финанслау өчен субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 7 декабрь, 1067 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм квалификация күтәрүгә, шулай ук эшмәкәрлек грамоталылыгын һәм эшмәкәрлек компетенцияләрен үстерүгә бәйле булган белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән файдалану буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен гаризалар сайлап алу конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 28 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм квалификация күтәрүгә, шулай ук эшмәкәрлек грамоталылыгын һәм эшмәкәрлек компетенцияләрен үстерүгә бәйле булган белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән файдалану буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен гаризалар сайлап алу конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 7 июнь, 393 нче;

«Кредитлау системасын үстерүгә Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 24 июнь, 432 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кредитлау системасын үстерүгә Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 24 июнь, 432 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 18 октябрь, 769 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\512.docx